КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 16 декабрь г.Казань № 1144

Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү чаралары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасын раслау турында» 2013 ел, 30 июль, 531 нче карары белән расланган «2014 – 2024 елларга Татарстан Республикасының урман хуҗалыгын үстерү» дәүләт программасы нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренә эшкә урнашкан урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү өчен бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне түбәндәгеләргә билгеләргә:

һөнәри белем бирү оешмасын тәмамлаган яшь белгечләргә – 150,0 мең сум күләмендә;

югары белем бирүче мәгариф оешмасын тәмамлаган яшь белгечләргә – 300 мең сум күләмендә.

2. Бу декарга теркәлгән Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибен расларга.

3. Бу карар 2020 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә дип билгеләргә.

4. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2019 ел, 16 декабрь, 1144 нче
карары белән расланды

Урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибе

I. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгы ведомствосы буйсынуындагы дәүләт учреждениеләренә эшкә урнашкан урман тармагының яшь белгечләренә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы бюджетыннан бер тапкыр акчалата түләү бирү тәртибе (алга таба – Министрлык, учреждение, бер тапкыр акчалата түләү, Тәртип), 2020 елдан башлап, урман хуҗалыгы өлкәсендә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирүче мәгариф оешмасын тәмамлаган елда учреждениегә белем алу турындагы һәм (яки) квалификация турындагы документта күрсәтелгән һәм бирелгән квалификация нигезендә эшкә урнашкан 30 яшькә кадәрге яшь белгечләргә (алга таба – яшь белгеч) бер тапкыр акчалата түләүләр бирү механизмын, күләмен һәм тәртибен билгели.

II. Бер тапкыр акчалата түләүне гамәлгә ашыру өчен нигезләр

2.1. Бер тапкыр акчалата түләү яшь белгечләргә Министрлык тарафыннан түбәндәге шартлар үтәлгәндә бер тапкыр бирелә:

2.1.1. 2020 елдан башлап, урман хуҗалыгы өлкәсендә белем бирү программалары буенча белем бирү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы һөнәри белем бирү оешмасын яки югары белем бирүче мәгариф оешмасын тәмамлаган елда учреждениегә белем алу турындагы һәм (яки) квалификация турындагы документта күрсәтелгән һәм бирелгән квалификация нигезендә эшкә (төп эш урыны буенча) урнашу.

2.1.2. Белем алу турындагы һәм (яки) квалификация турындагы документта күрсәтелгән һәм бирелгән квалификация нигезендә урман хуҗалыгы өлкәсендә белем бирү программалары буенча һөнәри белем алу турында дәүләт үрнәгендәге документ булу.

2.2. Бер тапкыр акчалата түләүне алу өчен Министрлык, яшь белгеч эшли торган учреждение һәм яшь белгеч арасында яшь белгечнең учреждениедә кимендә өч ел эшләү йөкләмәсе күрсәтелгән өчьяклы килешү булу зарури.

2.3. Бер тапкыр бирелә торган пособиене түләүдән баш тарту өчен яшь белгечнең бу Тәртипнең 2.1 нче пункты таләпләренә туры килмәве һәм Министрлыкка бу Тәртипнең 3.1 нче пункты белән күздә тотылган документлар тапшырылмау нигез булып тора.

## III. Документларны тапшыру тәртибе

3.1. Бер тапкыр акчалата түләү алу өчен яшь белгечләр агымдагы елның 25 декабренә кадәр (25 декабрьне кертеп) түбәндәге документларны Министрлыкка тапшыра:

3.1.1. Министрлык тарафыннан расланган форма буенча бер тапкыр акчалата түләү бирү турында гариза.

3.1.2. Министрлык тарафыннан расланган форма буенча шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә, тапшыруга һәм таратуга ризалык.

3.1.3. Учреждение җитәкчесе тарафыннан расланган түбәндәгеләрнең күчермәләрен:

белем алу турындагы һәм (яки) бирелгән квалификация белән квалификация турындагы документның;

эшкә кабул итү турындагы боерыкның;

хезмәт шартнамәсенең;

хезмәт кенәгәсенең;

паспортның (тутырылган барлык битләренең) яки шәхесне таныклый торган башка документның;

салым органында исәпкә кую турындагы таныклыкның;

индивидуаль (шәхсиләштерелгән) исәпкә алу системасында теркәлүне раслый торган документның.

## IV. Бер тапкыр акчалата түләү бирү турындагы гаризаны карап тикшерү тәртибе, бер тапкыр акчалата түләү бирү турында яки бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул итү

4.1. Бер тапкыр акчалата түләү бирү турындагы гариза һәм бу Тәртипнең 3 бүлегендә күрсәтелгән һәм теркәлә торган документлар яшь белгеч тарафыннан Министрлыкка тапшырыла, ул гаризаны һәм аңа теркәлә торган документларны алар кергән көннән 10 эш көне эчендә карап тикшерә һәм яшь белгечкә бер тапкыр акчалата түләү бирү турында яки бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тарту турында карар кабул итә.

4.2. Яшь белгечкә бер тапкыр акчалата түләү бирү турындагы яки бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тарту турындагы карар Министрлык тарафыннан боерык рәвешендә кабул ителә.

4.3. Министрлыкның бер тапкыр акчалата түләү билгеләү турындагы яки бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тарту турындагы боерыгы чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган биш көн эчендә яшь белгечкә язма рәвештә бер тапкыр акчалата түләү билгеләү турында яки бер тапкыр акчалата түләү бирүдән баш тарту турында хәбәрнамә җибәрелә.

4.4. Министрлык тарафыннан яшь белгечкә бер тапкыр акчалата түләү бирү турында карар кабул ителгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган 10 көн эчендә Министрлык бер тапкыр акчалата түләү турында өчьяклы килешү төзи. Өчьяклы килешүнең формасы Министрлыкның боерыгы белән расланa.

## V. Бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне күчерү һәм кире кайтару тәртибе

5.1. Бер тапкыр акчалата түләү бирү тиешле финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турындагы Татарстан Республикасы законы белән күздә тотылган бюджет ассигнованиеләре һәм бу Тәртипнең 1.1 нче пунктында күрсәтелгән максатлар өчен Министрлыкка бюджет акчасын алучы буларак билгеләнгән тәртиптә җиткерелгән бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә гамәлгә ашырыла.

5.2. Министрлык Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче булып тора һәм бер тапкыр акчалата түләү бирү турында өчьяклы килешү төзелгән көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә үзенең Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счетыннан бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү алучыларның кредит оешмаларында ачылган шәхси счетларына акча күчерүне гамәлгә ашыра.

5.3. Бу Тәртипнең 3.1 нче пунктындагы 3.1.3 нче пункытчасында күрсәтелгән һәм тапшырылган документлардагы мәгълүматларның дөреслеге өчен учреждение-ләр җитәкчеләре җавап бирә.

5.4. Яшь белгеч белән хезмәт шартнамәсе туктатылган очракта, учреждение бу турыда, эштән азат итү сәбәбен күрсәтеп, өч эш көне эчендә Министрлыкка язмача хәбәр итә.

5.5. Яшь белгеч тарафыннан учреждение белән төзелгән хезмәт шартнамәсе өч ел вакыт үткәнгә кадәр туктатылган очракта, Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 80 статьясы, 81 статьясының 3, 5, 6, 8, 11 нче пунктлары, 83 статьясының 4 һәм 8 нче пунктлары белән күздә тотылган нигезләр буенча яшь белгеч бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүнең бер өлешен хезмәт шартнамәсе туктатылган көннән 30 көн эчендә әлеге вакыт тәмамланганга кадәр калган көннәрдә фактта эшләнмәгән вакытка пропорциональ рәвештә билгеләнгән күләмдә Татарстан Республикасы бюджетына Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган Министр-лыкның шәхси счетына кире кайтарырга тиеш.

5.6. Әгәр дә яшь белгеч үз теләге белән бу Тәртипнең 5.5 нче пункты таләпләрен үтәмәгән булса, Министрлык бер тапкыр бирелә торган акчалата түләүне кире кайтару вакыты чыккан көннән эш көннәрендә исәпләнә торган җиде көн эчендә әлеге акчаны Татарстан Республикасы бюджетына законнар белән билгеләнгән тәртиптә түләттерү буенча чаралар күрә.

5.7. Россия Федерациясе Хезмәт кодексының 77 статьясындагы 5 нче пунктын-да каралган нигез буенча хезмәт шартнамәсе туктатылган очракта (хезмәткәрне аның үтенече буенча яки аның ризалыгы белән башка эш бирүчегә күчерү) һәм Татарстан Республикасының башка муниципаль районына учреждениегә эшкә күчергәндә, әгәр дә яшь белгеч әлеге вакыт эчендә учреждение белән хезмәт хокук мөнәсәбәтләрен дәвам итсә, бер тапкыр бирелә торган акчалата түләү күләме кире кайтарылмый.

5.8. Бюджет акчасын файдалануны тикшерүдә тотуны Министрлык башкара.

_______________